Татар теле.
9 нчы класс.
Укытучы Нурлыгаянова Л.Ш.

Тема: **Тиңдәш кисәкләре, гомумиләштерүче сүзләре булган җөмләләрдә тыныш билгеләре.**

Максат: тиңдәш кисәкләре, гомумиләштерүче сүзләре булган җөмләләрдә тыныш билгеләрен кую үзенчәлекләрен күнегүләр өстендә ныгыту.

Дәрес тибы – белемнәрне актуальләштерү.

Дәрес барышы:

I. **Мотивлаштыру-ориентлашу.**

1. а) психологик уңай халәт тудыру; **СЛАЙД1**

Елмай әле, син елмайсаң
Яратыр олы, кече,
Дөньядагы иң матур кеше-
Елмайган, көлгән кеше!

- Хәерле көн, укучылар! Бу шигырьдә сүз нәрсә турында?
- елмаю турында.
- Әйдәгез әле бер-беребезгә карыйбыз да елмаю бүләк итәбез. Дәресне елмаю белән башлыйбыз. Бу елмаю нурлары бөтен бүлмәбезгә таралсын. Һәрвакыт елмайыйк, көлеп яшик. Елмаю кешене бизи.

ә) белемнәрне актуальләштерү: Мин сезгә тест биреме таратам. Узган дәрес материалын тикшереп алырбыз.
Үзбәя.
3.УМ кую ситуациясе. 21 нче бирем.

Укытучы: Укучылар җөмләгә игътибар итегез әле. Монда нәрсәләр җитми? **СЛАЙД 2**
Җавап: Тыныш билгеләре.
Укытучы: Әйе, укучылар, тыныш билгеләре җитми. Сез тиешле урыннарга тыныш билгеләрен куеп языгыз. ( ЯЗАЛАР) Кайларга куйдыгыз? Ни өчен? Әйдәгез дөреслеген тикшерәбез.

К.ж.:*Дуслар рәтенә ул шушы төбәкнең җирен, күген,күктә йөзгән яшенле болытларын, урманда мәш килгән кырмыскаларын, җырлый-җырлый бал ташучы умарта кортларын - һәммәсен кертә иде.* **СЛАЙД 3**

*Бирелгән җөмләдә тыныш билгеләре тиңдәш кисәкләр һәм алар янындагы гомумиләштерәче сүз янында куелды. Димәк, без бүген шул хакта сөйләшербез.*

**Тактага һәм дәфтәрләргә тема языла.**

***Слайд 4.*** *Тиңдәш кисәкләре, гомумиләштерүче сүзләре булган җөмләләрдә тыныш билгеләре.*
**Слайд 5. Максат**

**II. УМ адымлап чишү.**

1. 144 нче күнегү. Вариантлап эшләү.

   1вариант -1,3,5 - так сандагы җөмләләр.

   2вариант 2,4,6 - җөп сандагы җөмләләр.

**Слайд 6**
К.ж.: Тиңдәш кисәкләр: **1**. Матур, җыйнак (кәрзиннәр) - тиңдәш аергычлар.
2.Бер кыз белән бер малай (кайтты) – тиңдәш ияләр.
**3**. Арып-талып, тәмамхәлдән таеп (кайтуыбызга карамастан) – тиңдәш хәлләр, иркенләп, рәхәтләнеп (ял итәргә язмаган) - тиңдәш хәлләр
4.Шатлык, шифа, моң(бүләк иттең) – тиңдәш тәмамлыклар.
**5**. Татар теле һәм әдәбияты (буенча лекция курслары) - тиңдәш аергычлар; әзерли, укыта,шөгыльләнүен дәвам итә – тиңдәш хәбәрләр; гарәп, фарсы, татар һәм төрек (телләрен) - тиңдәш аергычлар.
6. Оялам – туктый алмыйм – тиңдәш хәбәрләр.

*(Эшләп бирергәннән соң эшләрне партадашы белән алышып тикшерү.)*

**Слайд 7**.

*Нәтиҗә: Санау интонациясе булган урыннарда - өтер, 6 нчы җөмләдә,кискен каршы кую булганга, сызык куела.*

Үзбәя.

**Слайд 8**.

Мин төркемдәгеләргә җөмләләр бирермен. Мондагы җөмләләр якташ язучыбыз Айгөл Әхмәтгалиеваның ( Качкын авылы) әсәрләреннән алынган. Мин сезгә аның әсәрләрен укырга тәкъдим итәм. Сез гомумиләштерүче сүзләр һәм тиңдәш кисәкләрнең нинди җөмлә кисәкләре булуын билгеләгез. Гомумиләштерүче сүзләр янында тыныш билгеләрен аңлатыгыз. Телдән узара фикерләшеп эшләгез. (5-6 мин)

**Слайд 9**
К.ж.: 1. Инеш, чишмәләр, урамнар, тар тыкрыклар – һәммәсе – тиңдәш ияләр.
2. Барлык кошларны: песнәкләрне, саесканнарны, кызылтүшләрне, тукраннарны - тиңдәш тәмамлыклар.
3. Хәрәкәтен,йөз-кыяфәтен, буй-сынын, табигатен – барысын - тиңдәш тәмамлыклар.

***Слайд**10*
*Нәтиҗә: Тиңдәш кисәкләрдән соң килгән гомумиләштерүче сүз алдыннан **сызык** куела. Тиңдәш кисәкләр алдыннан килгән гомумиләштерүче сүздән соң**ике нокта** куела.*
Үзбәя.

***Слайд 11***
***ФИЗМИНУТ Микс-фриз-групп.*** *Көйгә хәрәкәтләнәләр. Көй туктагач сорау бирү:*

1. *Бию сүзендә ничә аваз бар (4)*
2. *Җөмлә кисәкләре ничәү? (5)*
3. *Без бүген класста ничәү? (9 җыю саны)*

*Әйдәгез,барыбыз да матур итеп басып,кулга-кул тотышыйк, бер-беребезгә елмайыйк та зур итеп кояш ясыйк. Куллардан-кулларга җылылык, күңелдән-күңелгә*

*рәхәтлек йөгерде, йөзләргә якты нур булып елмаю сирпелде. Менә шушы җылылык, рәхәтлек, елмаю безгә дәрес ахырына кадәр (көн буен) җитәрлек көч бирә дә инде.*

**Слайд 12. “2016 ел – Татарстанда су саклау зоналары елы”. Картина белән эш.**
Картина буенча тиңдәш кисәкләр кертеп 3-4 җөмлә төзетү

***Слайд13-15 МОДЕЛЬ***

***Слайд 15*** *БРТ га әзерләнү максатыннан тест биремнәре эшләү*
К.ж.: *1. ә; 2. а; 3. б; 4.а; 5. а.*

**III. Рефлексия, бәяләү.**
**Нәрсәгә өйрәндек?**
**Нинди яңалык белдек?**
**Белемнәрне кайларда кулландык?**
**Тагын кайларда кулланырга мөмкин?**
**Авырлык кайда очрады?**
**Сыйныфның (синең) эш нәтиҗәсе нинди?**
**Кемне мактый алабыз?**

1.« Дәрестә нинди УМ тикшердек?» соравына җавап бирү.
2.Дәрескә гомуми бәя кую.
(Укучылар бәяли. ни өчен үзенә шундый билге куя.Дәлилли.берничәсе генә)

4. Өй эше: 148 – 150 нче күнегүләр.

 ▲192. Текстны күчереп языгыз. Тиңдәш кисәкләрнең нинди җөмлә кисәкләре булуын ачыклагыз һәм асларына сызыгыз.

 ∆193. Әдәби әсәрләрдән тиңдәш кисәкләр янында гомумиләштерүче сүзләре булган 5 җөмлә сайлап языгыз.

 ∆194. “Мәрхәмәт елмаюдан башлана” исемле инша языгыз. Тиңдәш кисәкләр кулланырга тырышыгыз

Авыр булса да кайчакта
Елмай күз яшең аша,
Еш көл, елмай дусларыңа –
Көлү куңелне ача!